ШИМБӘ
27 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 21 (5821)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Мәктәп—комсомол эшенең әһәмиятле тармагы

Партиябез һәм Совет хөкүмәте яш буынны коммунизм рухында тәрбияләү мәсьәләләренә гаять зур игтибар бирәләр. Илебездә гомуми мәҗбүри башлангыч уку кертелде. Хәзер авылларда һәм милли республикаларда 7 еллык белем бирү, ә шәһәрләрдә 10 еллык белем бирү тормышка ашырыла.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды яш буынны коммунистик тәрбияләү эше буенча совет мәктәбе алдына гаять зур бурычлар куйды. Ленин—Сталин комсомолы бу җаваплы бурычларны үтәүдә совет укытучысына, мәгариф органнарына якыннан торып ярдәм итәргә тиеш. Комсомол совет мәктәбе белән берлектә, яш буынны тирән белемле итеп, Ватанга чын күңелдән бирелгән патриот итеп, хезмәтне яратучы итеп, кешелекнең иң яхшы сыйфатларын үзләштергән алдынгы, кыю һәм куркусыз көрәшче итеп большевизм рухында тәрбияләү эшенә чакырылган. Мәктәп—комсомол эшенең әһәмиятле тармагы.

Ләкин комсомолның күп кенә оешмалары бу әһәмиятле бурычны кирәгенчә аңлап җиткермәгәннәр әле. ВЛКСМ Үзәк Комитетының күптән түгел булып үткән X нчы пленумы комсомол оешмаларының мәктәп эшеннән, балаларны тәрбияләү һәм укыту бурычларыннан шактый дәрәҗәдә читләшүләрен, мәктәптә тиешле эш алып бармауларын, аңа икенче чираттагы эш итеп карауларын ачты һәм ул кимчелекләрне бетерү өчен конкрет юллар күрсәтте.

Күп кенә мәктәпләрдә укучыларның бер өлешенең укудан өлгермәү, бер класста 2 ел калу, дисциплинаны бозу һәм укытучыларга карата тупаслык күрсәтү фактлары яшәп килә. Татарстан республикасындагы мәктәпләрдә 1939—40 нчы уку елының беренче чирегендә укучыларның укудан өлгереше 77 процент, ә Казан шәһәре буенча 69,3 процент булды. Кайбер мәктәпләрдә өлгереш һаман да түбән булуында дәвам итә. Мәсәлән, Кукмара районының Янил мәктәбендә укудан өлгереш беренче чиректә 58 процент булса, икенче чиректә 56 процент. Сталин районының 35 нче номерлы мәктәбендә укучыларның 50 проценты түбән өлгереш бирде.

Күп кенә мәктәпләрдә комсомол һәм пионер оешмаларының эше ныклы юлга куелмау нәтиҗәсендә, байтак комсомолецларның һәм пионерларның укудан өлгермәү фактлары бар. Мәсәлән, Бауман районының 24 нче номерлы мәктәбендә икенче чиректә комсомолецларның 74 проценты һәм пионерларның 63,7 проценты гына укудан өлгерә. Молотов районының 26 нчы номерлы мәктәбендә 72 комсомолецтан 27 кешенең бердән алып 12 гә кадәр начар билгеләре бар.

Мәктәпләрдәге бу җитешсезлекләр өчен җаваплылык комсомол оешмалары өстенә дә төшә. Комсомолның күп кенә комитетлары мәктәп эшен яхшырту мәсьәләләре белән чын-чынлап шөгыльләнмиләр. Алар укытучылар белән даими элемтә тотмыйлар, укытучыларга карата дөрес булмаган мөнәсәбәтләргә юл куялар. Мәктәпләрдәге комсомол оешмаларының төп җитешсезлекләре әнә шунда.

Комсомол оешмалары ВЛКСМ Үзәк Комитетының күрсәтмәләрен тормышка ашыру өчен мәктәп эшен тирәнтен белергә, укучыларның укудан өлгерешен яхшыртуда һәм эчке тәртип кагыйдәләрен үтәүдә, социалистик ярышны җәелдерүдә, ныклы дисциплина урнаштыруда укытучыларга ярдәм күрсәтергә тиешләр. Мәктәпләрдә комсомол һәм пионер оешмаларын лаеклы кадрлар белән ныгытырга, аларның практик эшен мәктәп алдында торган бурычларга җавап бирерлек итеп оештырырга кирәк. Мәктәптәге барлык комсомолецларның һәм пионерларның уку һәм дисциплина ягыннан башкаларга үрнәк булуына ирешергә кирәк. Укучы балаларга культуралы ял оештыру, укучыларның иҗади инициативаларын үстерү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк. Мәгариф органнары белән берлектә балалар иҗадының күргәзмәләрен һәм смотрларын оештыру чараларын күрергә кирәк.

Балаларны коммунистик тәрбияләүдә укытучының тоткан роленә бәя биреп җиткермәү фактлары комсомолның Татарстан оешмасында да бар. Тархан, Норлат, Бондюг райкомоллары үткән елны укытучылар эшенә бәйләнешле бер мәсьәлә дә тикшермәгәннәр. Мондый фактларны комсомолның башка күп кенә оешмаларында да очратырга мөмкин. ВЛКСМ райкомнары һәм башлангыч оешмалар укытучылар белән кулга-кул тотынышып эшләргә, аларның авторитетын тагын да күтәрү өчен көрәшергә, X нчы пленум карарларын үтәү өчен көрәшне бергәләп оештырырга кирәк. Укытучыларның идея-политик дәрәҗәләрен һәм квалификацияләрен күтәрү, яш укытучылардан алдынгы иптәшләрне комсомолга тарту эше игтибар үзәгендә торырга тиеш.

Комсомол эшендә партия җитәкчелеге хәл иткеч урын тота. ВКП(б) райкомнары һәм башлангыч партоешмалар тарафыннан комсомол оешмаларының мәктәптәге эшен оештыруга көндәлек җитәкчелек һәм контроль таләп ителә. Мәктәпләрнең эшендәге җидди кимчелекләрне бетерүдә, комсомолның бу өлкәдәге эшен үрнәкле итеп куюда коммунистларның актив катнашын тәэмин итәргә кирәк. Мәктәп эшен яхшыртуда профсоюз оешмаларының, предприятиеләрнең, колхозларның һәм учреждениеләрнең, мәгариф органнарына һәм комсомол оешмаларына якыннан ярдәм итүләрен булдырырга кирәк.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты Москва, Ленинград һәм башка өлкәләрдәге күп кенә мәктәпләрнең мәктәп янында чәчәк, җимеш, яшелчә бакчалары төзү, тәҗрибә участкылары булдыру буенча күрсәткән инициативасын яклады. Бу бик яхшы инициативага Татарстан мәктәпләренең дә масса күләмендә кушылуын оештырырга кирәк. Комсомолның район һәм шәһәр оешмалары бу эштә мәктәпләргә тиешле булышлыкны күрсәтергә тиешләр.

Совет балаларын коммунизм рухында тәрбияләүдә яңа уңышларга ирешү өчен көрәшкә комсомол оешмаларын, хезмәт ияләрен тагын да ныграк туплыйк. Мәктәпләр эшен ВКП(б) ның XVIII нче съезды таләпләре югарылыгына күтәрик.

ТАТАРСТАН АССР НЫҢ XX ЕЛЛЫГЫН ҮТКӘРҮ БУЕНЧА ХӨКҮМӘТ КОМИССИЯСЕНЕҢ УТЫРЫШЫ

26 нчы гыйнварда Татарстан АССР Верховный Советында, Татарстан АССР ның XX еллыгын үткәрүгә хәзерлек буенча хөкүмәт комиссиясенең утырышы булды. Утырышны комиссия председателе иптәш Динмөхәметов алып барды. Комиссия үзенең утырышында Татарстан АССР ның XX еллыгына хәзерлек буенча Зеленодольск шәһәр комиссиясенең, Биектау һәм Питрәч район комиссияләренең отчетларын тыңлады.

Бу комиссияләрнең отчетлары буенча фикер алышуларда: Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе урынбасары Афанасьева, ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре Шәмсиева, Татарстан Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Идарәсе председателе Назаров, Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе урынбасары Сөләйманов, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе Динмөхәметов һәм ВКП(б) ның Өлкә Комитеты секретаре Алемасов иптәшләр катнаштылар.

Иптәш Алемасов үзенең чыгышында Татарстан АССР ның XX еллыгын үткәрүгә хәзерлек эшенең әле канәгатьләнерлек бармавын, бу эшкә кайбер җитәкче работникларның тиешле әһәмият бирмәүләрен, юбилейгә хәзерлек эше тирәсенә киң масса тупланмаганлыгын күрсәтү белән бергә, киләчәктә эшләү өчен конкрет такдимнәр кертте һәм ничек эшләү юлларын күрсәтте.

Комиссия утырышы Зеленодольск шәһәр комиссиясенең һәм Биектау район комиссиясенең Татарстан АССР ның XX еллыгын үткәрүгә хәзерлек буенча төзелгән планнарын нигездә кабул итеп, Татарстан АССР ның XX еллыгына хәзерлек эшенә хезмәт ияләренең киң массасын тартуны тәэмин итәрлек итеп яңадан карап чыгарга такдим итте.

Питрәч район комиссиясенең бу тарихи датаны үткәрүгә хәзерлек эшен хөкүмәт комиссиясе начар дип тапты һәм район комиссиясе председателе иптәш Тихоновка, әгәр дә ул хәзерлек эшен якын көннәрдә яшыртмаса, аңа карата чара күреләчәге турында кисәтеп куйды.

Комиссиянең киләчәк утырышы 14 нче февральдә булачак. Анда политик-агарту учреждениеләренең бу датага хәзерлекләре турында Татарстан АССР Мәгариф Халык Комиссары иптәш Контюковның отчеты һәм берничә район комиссияләренең отчетлары тыңланачак.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПАДАГЫ СУГЫШ

ПАРИЖ, 24 гыйнвар. (ТАСС). Фронттагы хәл турында белдерүендә Гавас агентлыгы түбәндәгечә күрсәтә: „Көчле салкын булуга карамастан, патрульләрнең хәрәкәтләре актив рәвештә барды. Виссембургтан бераз көнчыгышка табарак, Лаутер елгасының югарыгы өлешендә, Германия патруле Франциянең кечкенә постларыннан берсен кинәт кенә басып алырга маташты. Атака кире кайтарылды. Каршы якның берничә кешесе үтерелде. Французлар бер плен алдылар. Лотариндия фронтында германнар отряды Франция патрулен тозакка эләктетерергә маташты. Ике арада таң вактында башланып киткән сугыш нәтиҗәсендә Франция патруле чолганыштан котылуга ирешә. Немецлар бер плен алдылар. Томан һәм салкын аркасында авиация хәрәкәтләре булмады“.

ЛОНДОН, 24 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының радио буенча хәбәр итүенә караганда, бүген көндез Шотландия атаулары өстендә зур биеклектә 3 самолет килеп чыккан. Аларны Германия самолетлары дип уйлыйлар. Самолетлар берничә бомба ташлаганнар, дип хәбәр итәләр, ләкин бу хәбәр әле расланмаган.

ПАРИЖ, 25 гыйнвар. (ТАСС). Парижда кичә кич һәм бүген иртә белән игълан ителгән рәсми белдерүләрдә, фронтта „яңа бер нәрсә дә булмады“ дип күрсәтелә.

БЕРЛИН, 25 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе болай хәбәр итә: „Көнбатышта аеруча бер төрле вакыйгалар дә булмады. Хәрби һава берләшмәләре Англия өстендә разведка очышлары үткәрделәр. Сугыш башланганнан бирле Атлантик океанда операцияләр алып барган „Дейчланд“ броненосецы күптән түгел генә ватанга кайтты“.

Англиянең нейтраль илләрне сугышка тарту планнарын Германия матбугаты фаш итә

БЕРЛИН, 25 гыйнвар. (ТАСС). Сугыш хәрәкәтләре күләмен киңәйтүгә һәм сугышны нейтраль илләр территориясенә күчерүгә карата Англия—Франция омтылышларын Германия газеталары фаш итүдә дәвам итәләр. „Дейче альгемейне цейтунг“ газетасы „Британиянең 2 нче номерлы сугыш планы“ дигән баш мәкаләсендә түбәндәгечә яза: „Англия, нейтраль илләрне үзенең сугыш авантюрасына кертеп буташтыру теләген куеп, төрле төстәге хәйләләрне куллана. Башта нейтраль илләрнең нинди куркыныч алдында торулары турында сөйләнә, аннан соң, оятсыз рәвештә, алар артында Англия торганлыгы әйтелә һәм Англиянең „аларга ярдәм күрсәтү“ өчен бары тик уңайлы хәлне генә көтеп торуы белдерелә. Төньяк дәүләтләреннән берсенең чит ил эшләре министре күптән түгел генә Англиянең чын теләкләрен ачып салды. Бу министр, көнбатыш фронтта союзникларның хәле куркыныч алдында тора һәм шуңа күрә союзниклар сугышны нейтраль илләр территориясенә күчерергә омтылалар, дип белдерде“.

Аннан соң, Англиянең баштагы сугыш планыннан бер нәрсә дә калмаганлыкны күрсәтеп, „Дейче альгемейне цейтунг“ газетасы,— Англия сугышны флангыларда җәелдереп җибәрергә омтыла һәм шуның өчен хәзерендә сугышмаучы илләрне үзенә хезмәткә куярга тели, дип аеруча күрсәтә. Газета болай ди: „Германия белән Советлар Союзы арасында каршылык тудырырга мөмкин булмаганлыктан, союзниклар нейтраль илләрне сугыш кырына әйләндерергә телиләр. Англиянең икенче номерлы сугыш планының мәгънәсе әнә шуннан гыйбарәт“.

АНГЛИЯ—ЯПОНИЯ МӨНАСӘБӘТЛӘРЕНЕҢ КИСКЕНЛӘШҮЕ

ТОКИО, 25 гыйнвар. (ТАСС). „Кокумин“ газетасы үзенең киң рәвештә язылган мәкаләсендә илдә Англиягә каршы хәрәкәтнең үсүе турында хәбәр итә. Япониянең „Асама-Мару“ пароходын туктатуны һәм тентүне, 21 немец пассажирын алуны төрле оешмалар Японияне мәсхәрәләү дип карыйлар, ди газета. Күп кенә газеталар Токиода Англия илчелеге йорты янында Англиягә каршы демонстрация турында хәбәр итәләр.

„Миако“ газетасы „Англия—Япония мөнәсәбәтләренең кискенләшүе“ дигән баш мәкаләсендә, илдә Англиягә каршы хәрәкәтнең Англия белән Япония арасындагы мөнәсәбәтләрдә яңа кискенлек тудыруын аеруча күрсәтеп үтә. Газета, „Асама-Мару“ белән булган инцидент халыкара хокукны бозу һәм Японияне һич гафу ителмәслек рәвештә мәсхәрәләү булып тора, дип саный. Газета: „Англиянең хәрәкәтләре халыкара хокук принциплары турында фикер йөртү рамкаларыннан тышка ук чыкканлыктан һәм дәүләтнең игътибары турындагы мәсьәлә булып торганлыктан, Япония үз-үзен саклау буенча чаралар күрергә тиеш“ дип белдерә.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуандун провинциясенең үзәк өлешендә кытай гаскәрләре 23 нче гыйнварда Саньцзянны (Кантоннан төньяк-көнбатышка таба 40 километрда) алдылар һәм 24 нче гыйнварда Кантон—Самшуй тимер юлы линиясенә чыктылар.

22 нче гыйнварда кытай партизаннарының зур отряды Сяодунга (Наньнин—Циньчжоу шоссесе) үтеп керде. Урам сугышында партизаннар японнарның 300 гә якын солдатын үтерделәр. Партизаннар японнарның хәрби складын яндырдылар.

Үзәк Кытайда

Чжэцзян провинциясенең төньяк өлешендә кытай һәм япон гаскәрләре арасында зур сугышлар бара. 21 нче гыйнварда япон гаскәрләре, самолетлар ярдәме белән, зур югалтулар биреп, Цзяньтан елгасын (Ханчжоудан көньякта) аркылып чыктылар. 24 нче гыйнварда япон командованиесе Сяошань районына 4,5 меңгә якын кеше күчерде, бу көчләр Сяошань станциясен басып алдылар. Япон гаскәрләренең бер колоннасы, көнбатышка таба хәрәкәт иткән хәлдә, көчле каршылыкка очрады һәм Сяошаньга чигенде. Японнарның икенче колоннасы Сяошаньнан көньякка таба 25 километр алга китте.

„Синьвеньвеньбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, шушы көннәрдә кытай партизаннары японнарның Цзясин (Шанхай—Ханчжоу тимер юлында) бистәләрендә урнашкан гарнизоннарына каршы күп кенә атакалар ясаганнар. Партизаннар японнарга зур зарар китергәннәр һәм, аерым алганда, амуниция складын юкка чыгарганнар. Японнарның югалтулары 5 миллион долларлык дип исәпләнә. 22 нче гыйнварда партизаннар, Цзясин районында тимер юл полотносын сүтеп, хәрәкәтне туктатканнар.

Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә, Суйчжоудан төньяк-көнчыгышта, японнарның Гаоченнан чигенеп баручы 4 мең кешелек отряды кытай гаскәрләре тарафыннан әйләндереп алынган хәлдә калды. Чжунсян районында (Ханькоудан төньяк-көнбатышта) кытай һәм япон гаскәрләре арасында тагын сугышлар башланды.

Төньяк Кытайда

Шаньси провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә, Линьцзиндә, японнарның 300 кешелек отряды баш күтәрде. Баш күтәрүчеләр япон гарнизонына каршы сугышырга керештеләр һәм японнарның бик күп солдатларын һәм офицерларын үтерделәр.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

В. В. КУЙБЫШЕВ ИСТӘЛЕГЕ

РЕВОЛЮЦИЯ МУЗЕЕ ДОКУМЕНТЛАРЫ

Ялкынлы большевик Валериан Владимирович Куйбышевның, уң-троцкичы контрреволюцион банда тарафыннан явыз рәвештә үтерелүенә 25 нче гыйнварда биш ел тулды.

СССР ның Революция музеендә В. В. Куйбышевның тормышын һәм революцион эшен күрсәтә торган документлар саклана. Кукчәтау шәһәрендәге (хәзер Казагстан ССР да) йортның фоторәсемнәре бар. Валериан Владимирович үзенең балалык һәм яшьлек елларын шул шәһәрдә үткәргән. Шулай ук музейдә, Валериан Владимирович укыган мәктәп йортының рәсеме бар. 1909 нчы елда патша охранкасы бүлеге 20 яшьлек пролетар революционер Куйбышевка регистрация карточкасы керткән. Бу регистрация карточкасының фотографиягә алынган күчермәсе музейдә саклана. В. В. Куйбышевның 1907 нче елга—аның Каинский шәһәрендә (Себердә) беренче тапкыр сөргендә булган чорына, Нарымда сөргендә (1912 ел) һәм Самара төрмәсендә (1916 ел) булган чорына караган фото-портретлары саклана.

Валериан Владимировичның портреты гражданнар сугышына багышланган залга куелган.

Революция музееның документаль материаллары В. В. Куйбышевның якты образын гаять яхшы рәвештә күрсәтәләр. (ТАСС).

ВКП(б) ТАРИХЫ ТЕМАЛАРЫНА ХУДОЖЕСТВО ӘСӘРЛӘРЕ КҮРГӘЗМӘСЕ

СССР Совнаркомы янындагы сәнгать эшләре комитеты ВКП(б) тарихы темаларына художество әсәрләре күргәзмәсе оештыруга хәзерлек башлады.

Күргәзмә өчен төрле әсәрләрдән барлыгы 300 гә якын әсәр: рәсемнәр, акварельләр, гравюралар, офортлар, литографияләр хәзерләнәчәк. Бу эшкә барлык союзный республикаларның художниклары тартыла.

ВКП(б) тарихы темаларына эшләүче художниклар өчен СССР ның сәнгать работниклары үзәк йортында индивидуаль консультация оештырылды. Художникларга консультация, шулай ук, Маркс—Энгельс—Ленин Институты һәм В. И. Ленин Үзәк Музее работниклары тарафыннан да биреләчәк.

Күргәзмәне шушы елның 9 нчы сентябрендә—„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ чыгарылуның икенче еллыгы көненә ачарга карар бирелде. (ТАСС).

Москвада, гражданнар һава флотының үзәк йорты.
А. Межуев фотосы (ТАСС фото-клишесе).

„ЧЕХОВ ҺӘМ ГОРЬКИЙ“

А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕНДӘ ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

А. М. Горький музее А. П. Чеховның туууна 80 ел тулу көненә „Чехов һәм Горький“ дигән темага күргәзмә ача. Күргәзмәнең экспонатлары русның бу ике бөек язучысының дуслыгын, аларның иҗад юлларын күрсәтәләр.

Күргәзмәдә Чеховның Горький турындагы һәм Горькийның Чехов турындагы фикерләре язылган материаллар куелачак. Күргәзмәгә килүче кеше Антон Павловичның Фәннәр академиясенә язган атаклы хатының фото күчермәсен күрәчәк. Бу хатта ул Горькийны почетлы академик исменнән мәхрүм итүгә каршы протест белдерә һәм шушы уңай белән үзен дә академик дип санамауларын сорый. Шунда ук Горькийның аерым әсәрләре турында, аерым алганда „Фома Гордеев“ турында, язучының фикерләрен укырга мөмкин.

Витриналарның берсе „В. И. Ленин һәм И. В. Сталин мәкаләләрендә һәм речьләрендә А. П. Чехов персонажлары“ дигән темага багышлана.

Чеховның Горькийга биргән һәм күргәзмәгә куела торган бүләкләре зур кызыксынуга лаеклы материал булачаклар. Алар арасында кесә сәгате һәм: „М. Горькийга д—р Чехов, 1899 ел“ дип язылган фотография бар. (ТАСС).

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ УКАЗЫ

Батальонный комиссар Д. А. БАЛАХАНОВКА һәм кызыл армеец А. Г. КОЙДАГА Советлар Союзы герое дигән исемне бирү турында

Фин ак гвардиячеләренә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәүләре өчен һәм бу эштә батырлык һәм геройлык күрсәткәнлекләре өчен **Ленин ордены** һәм **„Алтын йолдыз“** медале тапшырып, батальонный комиссар Дмитрий Александрович **Балахановка** һәм кызыл армеец Анатолий Григорьевич **Койдага** Советлар Союзы герое дигән исемне бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 26 гыйнвар, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

25 нче гыйнварда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

1940 нчы ел, 28 нче гыйнварда кич сәгать 6 да Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы) социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе ачыла.

Көн тәртибендә:

1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар. (Докладчы ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев).

Киңәшмәгә килүче делегатларны Казан вокзалында беренче номерлы залда Татнаркомзем дежурные каршылый.

Делегатларны регистрацияләү Татнаркомзем бинасында 16 нчы бүлмәдә үткәрелә. Телефоннар 8—15 һәм 32—20.

ОЕШТЫРУ КОМИССИЯСЕ.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

УҢЫШЛАРНЫ ӨЗЛЕКСЕЗ НЫГЫТЫЙК

Аксубай районында 1.000 нән артык кеше партия тарихын үзлегеннән һәм 145 кеше түгәрәкләрдә өйрәнә.

Аксубай МТС ы янындагы партоешмада учетта торучы коммунистлардан Белов, Камалеттинев, Убайкин, Мясников һәм Лукин иптәшләр партия тарихын өйрәнүдә үрнәк булырлык күрсәткечләр бирәләр. Партия тарихын өйрәнә башлаганнан соң токарь иптәш Краснов үзенең эшен шактый яхшыртты. Ул, производствода стахановчы, Аксубай МТС ы эшчеләре һәм хезмәткәрләре аны рабочкомга председатель итеп сайладылар һәм ул бу эшне яхшы үти.

Комбайнчылар Димитриев, Мортазин һәм тракторчы Федоров иптәшләр дә үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшләүләре нәтиҗәсендә агитаторлар булып эшләү дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Партоешма секретаре иптәш Ленцов партия пропагандасы эшенә яхшы җитәкчелек итә, коммунистларны идея-политик яктан тәрбияләүдә большевикларча эшли.

„Үсәр“ колхозы янындагы партоешма да (секретаре иптәш Валиуллин) „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүчеләргә якыннан торып җитәкчелек итә. Бу оешмадагы коммунистларның күбесе партия тарихын үзлегеннән өйрәнә. Коммунист иптәш Фасахов „кыскача курс“ның 8 бүлеген өйрәнеп, конспект төзеде. Иптәш Фасахов Ленин—Сталин әсәрләреннән киң күләмдә файдалана, художество әдәбияты китапларын системалы рәвештә укый. Шул ук колхозда комсомолка иптәш Заһидуллина да 8 бүлекне өйрәнү эшен төгәлләде. Ул яхшы агитатор, халык арасында зур авторитет яулап алды һәм район советына депутат итеп сайланды.

Саугач авылынннан Стеколов, Иске Ильдирәк авылыннан Игнатьев, Яңа Ибрай авылыннан Зәйнуллин, Иске Тимошка авылыннан Герасимов иптәшләр дә партия тарихын өйрәнү өстендә тырышып эшлиләр.

Саугач, Иске Тимошка авылларындагы, „Большевик“ совхозындагы һәм педучилищедәге партоешмаларда учетта торучы коммунистлар партия тарихын үзлекләреннән өйрәнәләр. Бу башлангыч оешмаларда консультацияләр һәм иптәшләрчә беседалар системалы рәвештә үткәрелә.

Бездә марксизм-ленинизм теориясен яхшы үзләштергән алдынгы кешеләр үсеп чыктылар. Иптәш А. Н. Камзин ТАССР Верховный Советына депутат итеп сайланды, хәзер ул район башкарма комитеты председателе булып эшли. Иптәш С. М. Калугин район башкарма комитетының кадрлар бүлеге мөдире булу дәрәҗәсенә җитте һәм район Советына депутат итеп сайланды. Рядовой колхозчы иптәш Гайнеттинов колхоз председателе булып эшли, зур хуҗалыкка оста җитәкчелек итә, „Татарстан“ колхозы колхозчылары аны район Советына депутат итеп сайладылар.

Район Советына депутат итеп сайланган укытучы орденлы Г. Ф. Федоров, Тимошкино МТС ының өлкән агрономы Л. С. Петров, укытучы Л. А. Помыкало иптәшләр дә марксизм-ленинизмны бик яхшы үзләштерәләр.

Парткабинет тарафыннан шактый зур эшләр үткәрелде. „ВКП(б) тарихының кыскача курс“ ы буенча район үзәгендә 7 тапкыр, СССР тарихы буенча 5 тапкыр лекция укылды. Район үзәгендә дә, авылларда да групповой һәм индивидуаль консультацияләр, иптәшләрчә беседалар үткәрелә.

Үзләренең политик белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшләүче иптәшләр белән бергә, политик белем дәрәҗәләрен күтәрү эше белән начар шөгылләнүче коммунистлар да бар әле. Мәсәлән, Гатауллин (Яңа Ибрай авылы), Мусин (Иске Ибрай авылы), Сорокин (Иске Тимошка авылы) иптәшләр теоретик артталыкларын бетерү өстендә эшләмиләр, марксизм-ленинизм теориясен өйрәнмиләр.

ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге бу өлкәдә башлангыч партоешмаларга канәгатьләнерлек җитәкчелек итми әле. Шунлыктан кайбер башлангыч партоешмаларның секретарьлары массаның идея тормышына дөрес һәм көндәлек рәвештә җитәкчелек итә алмыйлар.

Пропаганда һәм агитация бүлеге интеллигенциянең „кыскача курс“ ны ничек өйрәнүен белми. Район газетасы да пропаганда мәсьәләләрен бик аз яктырта, 1939 нчы елның октябрь—декабрь айларында „кыскача курс“ны өйрәнү буенча район газетасында бер генә хәбәр дә урнаштырылмаган.

Пропаганда һәм агитация бүлеге работниклары урыннарда бик аз булалар, коммунистларның укуын оештыру эшендә башлангыч партоешмаларга тиешле ярдәм күрсәтмиләр.

Партия пропагандасы эшендәге бу кимчелекләр ашыгыч рәвештә бетерелергә тиеш.

П. Галкин.

ВКП(б) ның Аксубай райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

Агитация эшендә комсомол инициативасы

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларны үткәрүдә Татарстан комсомолецлары гаять зур инициатива күрсәттеләр. Республикабызда 25 меңнән артык комсомолец һәм союздан тыш яшьләр сайлауларга хәзерлек эшенә катнаштылар. Алар, большевистик агитаторлар булараk, бөек Сталин Конституциясен, партия һәм хөкүмәт карарларын киң массага аңлату буенча зур эш алып бардылар.

Хәзер комсомолның күп кенә оешмалары советларга сайлаулар кампаниясе вактындагы уңышларны ныгыту һәм агитация - масса эшен өзлексез дәвам иттерү чараларын күрәләр. ВЛКСМ ның Киров райкомы комсомолның башлангыч оешмалары секретарьлаpе белән киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә агитаторларның эш тәҗрибәләренә йомгак ясалды һәм агитация эшләрен системалы рәвештә дәвам иттерү бурычлары турындагы мәсьәлә тикшерелде. Комсомолның Ленин райкомы да агитация эше буенча шундый ук практик чаралар үткәрде.

Күп кенә комсомолец-агитаторлар үзләренең мактаулы эшләрен дәвам иттерәләр. Мәсәлән, Чаллы районы, Иске Гәрдәле авылының комсомол комитеты секетаре иптәш Г. Хәйруллин советларга сайлаулардан соң колхозчылар массасы арасында Сталинның биографиясен өйрәнүне оештырды. Хәзер Ленинның биографиясен өйрәнү эшен алып бара. Молотов исемендәге колхозда укытучы комсомолец иптәш Галиев халыкара хәл мәсьәләләре турында докладлар үткәрүне оештыра. Свияжский авылында (Югары Ослан районы) комсомолка иптәш Мария Казанцева кунарга туктаган йөкчеләр, колхозчылар арасында партия һәм хөкүмәт карарлары, халыкара хәл мәсьәләләре турында беседалар үткәрә. Политик агитация эшен шулай системалы рәвештә алып баручы агитаторларны күпләп санарга мөмкин.

Шулай да әле кайбер районнарда сайлаулардан соң масса-агитация эшен дәвам иттерүгә җидди игтибар бирмиләр. Мәсәлән, Питрәч райкомолы (секретаре иптәш Никифоров) районда күпме агитатор үзенең эшен ничек дәвам иттерүен ачык белми. Биектау райкомолы да бу эшне оныткан. Агитация эшен системалы рәвештә алып бару һәм тәҗрибәләрне уртаклашу мәсьәләсе белән ВЛКСМ райкомнары көндәлек рәвештә шөгылләнергә тиешләр.

Кайбер авыл районнарында масса-агитация эшен хуҗалык бурычларына, язгы чәчүгә хәзерлек эшләренә бәйләп алып баруга җитәрлек игтибар бирелми. Комсомолның башлангыч оешмаларына производство мәсьәләләре буенча практик ярдәм күрсәтелми. Мисальгә Биектау районын алырга мөмкин. Райондагы күп кенә колхозларда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт башланмаган, агро-зоотехника укулары оештырылмаган. Менә бу җидди кимчелекләрне бетерүдә, язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнүдә комсомолның башлангыч оешмалары зур инициатива күрсәтергә тиешләр иде. Ләкин райкомол бу мәсьәлә белән конкрет рәвештә шөгылләнми.

Партиябез политик агитация эшендә комсомолга зур ышаныч баглый. ВЛКСМ ның район комитетлары һәм башлангыч оешмалары агитация-масса эшен өзлексез дәвам иттерергә, партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең карарларын үтәү өчен көрәшкә комсомолецларны һәм барлык яшьләрне тагын да ныграк тупларга бурычлылар. Бу җаваплы һәм мактаулы эштә төп игтибарны агитация эшенең сыйфатына, комсомол инициативасының яңа үрнәкләрен күрсәтүгә юнәлдерергә кирәк.

Г. Шәмсиева.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре.

Карарлар күп, эш кенә юк

2 нче номерлы ТЭЦ (Казан) янындагы комсомол оешмасында пропаганда эшен оештыру буенча карарлар һәм резолюцияләр бик күп чыгарылды. Пропаганда мәсьәләсе гомуми җыелышларда һәм комитет утырышларында берничә тапкыр куелды. Ләкин бу өлкәдә борылыш һаман да юк.

Оешмада 106 комсомолец бар. Комитет секретаре иптәш Прокофьев, комсомол оешмасында пропаганда эшенең куелышы турында бер нәрсә дә әйтә алмый. Ул: „Бу мәсьәлә буенча безнең комитет члены иптәш Касыймов эшли“ дип, җаваплылыкны үз өстеннән алып ташламакчы була.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н комсомолецлардан бары 15 кеше үзлегеннән өйрәнә, аларның ничек өйрәнүләрен иптәш Прокофьев белми, алар белән бер төрле дә фикер алышу үткәрми.

Комсомолецларның соравы буенча түгәрәк оештырылган булса да, анда занятиеләр үткәрелми. Иптәш Прокофьев үзе „кыскача курс“ның беренче бүлеген дә өйрәнеп бетермәгән.

Бу хәлне ВЛКСМ ның Ленин райкомы белә. Ләкин ул комсомол комитетына пропаганда эшен оештыруда ярдәм итми. Райкомолның пропаганда - агитация бүлеге мөдире иптәш Арсеевич та бу эшне юлга салу белән тиешенчә кызыксынмый. Карарлар күп, ә эштә һаман да борылыш башланганы юк.

А. Овчинников.



Казмехкомбинатның Ильич исемендәге механика заводы фрезеровчигы, ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш А. Л. Жуков ике станокта эшләп 1939 нчы елның еллык производство планын 257,3 процентка үтәде. РӘСЕМДӘ: иптәш Жуков эш вактында. И. Галиев фотосы.

УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ КОМСОМОЛ АКТИВЫ ҖЫЕЛЫШЫ

23 нче гыйнварда, укытучылар йортында, Казан шәһәрендәге укытучыларның һәм комсомол активының җыелышы булды.

Җыелыш почетный президиумга ВКП(б) Үзәк Комитетының политбюро составын: Сталин, Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Микоян, Андреев, Жданов, Хрущев, Берия һәм Шверник иптәшләрне сайлады.

Комсомолның Өлкә Комитеты секретаре иптәш Г. Шәмсиева ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы йомгаклары турында доклад ясады.

Доклад буенча фикер алышуларда катнашучы иптәшләр партиябезнең Үзәк Комитеты инициативасы буенча чакырылган бу пленумның карарлары комсомолецлар һәм укытучылар тарафыннан гаять зур политик күтәренкелек белән каршы алынуын әйттеләр.

74 нче мәктәп укытучысы иптәш Девятов, ВЛКСМ ның Молотов райкомы мәктәптәге комсомол һәм пионер оешмалары эшенә бик формаль каравын тәнкыйть итте. Өлкән вожатыйлар бик еш алмаштырылалар. Кайбер вожатыйлар эшләү урнына, эшне ничек тә тизрәк тапшырып китү ягын карыйлар. Бу хәл пионер оешмалары өчен кадрлар сайлап алуга райкомның җидди игтибар итмәвен күрсәтә. Мәктәптәге комсомол оешмасы укытучылар белән бергәләп эш итәсе урында, киресенчә, комсомол җыелышларына укытучыларны кертмәүгә кадәр барып җитә.

Иптәш Малкин (19 нчы мәктәп директоры) мәктәптә укытучылар коллективының һәм комсомол оешмасының бергәләп яхшы гына эшләп килүләре турында сөйләде. Комсомол оешмасы мәктәп эшендә үзен җаваплы итеп сизә, укучылар белән җыелышлар үткәргәндә аңлашып эшли. Мәктәп эше турында директорның информацияләрен тыңлап, эшне тагын да яхшырту чараларын билгели. Шулай да әле комсомол оешмасының эшендә кимчелекләр, бигрәк тә ВЛКСМ сафларына кабул итү мәсьәләсенә бик җиңел караулар бар. Комсомолга иң алдынгы укучыларны сайлап ала белмәү фактлары очрый.

33 нче мәктәпнең өлкән вожатыйы иптәш Ляпин укучыларның ата-аналары өчен политика һәм педагогика мәсьәләләре буенча лекцияләр, консультацияләр оештырырга һәм бала тәрбиясе мәсьәләләре турында матбугатта киң яктыртырга кирәклеген әйтеп үтте.

Иптәш Фридман (41 нче мәктәп укытучысы) пионер оешмасы эшенә Бауман райкомолы конкрет җитәкчелек итмәү турында сөйләп, күп кенә фактлар китерде. Анда пионерга кабул итү мәсьәләсендә зур бозулар килеп чыккан. Мәктәптә бер класстагы укучыларның барсын да, персональ тикшереп тормыйча, тулаем кабул итү фактлары булган.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Гаязеттинов речь белән чыкты. Ул, шәһәр мәктәпләрендә укудан өлгереш һәм аңлы дисциплина өчен көрәшнең канәгатьләнерлек булмавын конкрет мисаллар белән күрсәтте, мәктәпләрдә комсомол һәм пионер оешмаларының эшен яңача үзгәртеп кору бурычларына тукталды.

Җыелыш ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы карарларын бердәм рәвештә яхшы дип тапты һәм аларны тормышка ашыру буенча конкрет чаралар билгеләде.

Сугыш уты кабызучыларның тезгенендә

Финляндиянең ак бандитларына „ярдәм“ сылтавы астында Англия—Франция империалистлары Скандинавия илләрен сугышка тарту өчен котырынып кампания алып баралар. Скандинавия ярым атавы өстеннән Англия—Франция империализмының үз контролен куярга һәм аны Германиягә каршы сугыш мәйданына әйләндерергә омтылуы бу кампания барышында торган саен ачыграк күренә бара. Маннергейм Финляндиясенә „ярдәм“—ул, Англия—Франция империалистлары блогының бик тирән киткән планнарын тормышка ашыру өчен уңайлы каплавыч кына.

Чит ил матбугаты хәбәрләреннән күренүенчә, Скандинавиядә сугыш мәйданы оештыру планы 1939 нчы елның декабрендә союзникларның Парижда булган верховный совет утырышында һәр яклап тикшерелгән. „Тан“ ның һәм башка француз газеталарының язуларына караганда, бу утырышта Милләтләр лигасының „Финляндиягә ярдәм“ итү турындагы карарларын тормышка ашырырга булышлык итәрлек методлар тикшерелгән. Будапешттагы „Пестер Ллойд“ газетасының Париждагы хәбәрчесе әйтүенчә, союзникларның верховный советы Европада сугыш мәйданын киңәйтергә кирәк дигән нәтиҗәгә килгән, чөнки, газетаның язуынча, „Англия һәм Франция Швециянең һәм Норвегиянең чикләре һәм табигый байлыклары куркыныч астында калуга юл куя алмыйлар“.

Швециянең һәм Норвегиянең „чикләрен һәм табигый байлыкларын“ саклау бурычын үз өсләренә алып, Англия һәм Франция, барыннан да элек, Германияне Швеция һәм Норвегия рудасыннан аерырга омтылалар.

Сугышның беренче көннәреннән үк инде Англия Швециягә һәм Норвегиягә политик һәм экономик басым ясау юлы белән, бу илләрнең Германия белән сәүдә итүләренә һәм аерым алганда аларның Германиягә кирәкле руданы һәм башка төрле чималны сатып торуларына тоткарлык ясарга тырышты. Бу тырышулар уңышсыз чыкты. Скандинавия илләре, нейтралитет позициясендә калганнары хәлдә, Германия белән яңа сәүдә килешүләре төзеделәр. Хәзер инде Скандинавия илләрен нейтралитетны Англиянең һәм Франциянең сугыш максатларына яраклаңдырырга мәҗбүр итү өчен Англия—Франция сугыш блогы аларга басымны көчәйтә.

Англия—Франция планнарына Швеция һәм Норвегия буржуазиясенең күренекле кешеләре генә түгел, хәтта социал-демократиянең реакцион лидерлары да бик нык булышлык күрсәтәләр.

Күптән түгел генә Швеция социал-демократиясенең үзәк органы „Социал-Демократен“ газетасы, Англиянең һәм Франциянең Германиягә каршы җәелеп бара торган сугышында социал-демократия Англиягә һәм Франциягә булышлык итәргә тиеш дип язды, чөнки,— ди газета,—бу „парламент демократиясе“ илләрендә эшчеләр сыйнфы „иң зур ирекләргә“ һәм үзенең „материаль тормыш дәрәҗәсе күтәрелүгә“ ирешә.

Социал-демократ лидерларның бу позициясе буржуазиянең реакцион даирәләренең сугыш пропагандасы алып баруларын шактый җиңеләйтә.

Скандинавия илләре сугышта актив катнаша калганда бик күп табыш алачакларын алдан сизеп, Швециянең сугыш концерннары Швециядә „промышленность мобилизациясен“ киңәйтү өчен системалы кампания алып баралар. Бу концерннарның интересларын яклаучы „Стокгольмс Тиднинген“ газетасы, Швеция оборонасы ягыннан гына түгел, бәлки „Финляндиягә ярдәм“ оештыру ягыннан караганда да Швециянең сугыш промышленностын тагын да үстерүне тизләтергә кирәк дип көн саен язып килә.

Швециядә сугыш настроениеләренең кабынуы Англиянең—Франциянең Швецияне Скандинавия ярым атавында сугыш хәрәкәтләренең төп таяныч базасына әйләндерү планын тормышка үткәрүгә шактый ярдәм итә. Швеция хөкүмәтенең эчке политик чаралары да шуңа ук булышлык итәләр.

Шушы көннәрдә Швеция риксдагы сугыш һәм сугыш куркынычы була калганда „дәүләтне саклау“ турында закон кабул итте. Бу закон демократик ирекләрне чикләүне күздә тота. Бу законның үткен башы эшчеләр сыйнфына каршы юнәлдерелгән һәм ул—Швецияне сугышка тарту юлында әһәмиятле чара. Хөкүмәтнең тышкы политик планнарына да бәйләнешле булган бу реакцион закон Швециядә һәм Скандинавиянең башка илләрендә ачу китереп чыгарды. Швед халкының киң массасы арасында Швеция политикасының киләчәге өчен курку көчәя.

Сугышка каршы настроениеләрнең үсүе Скандинавия илләренең эш башында утыручыларын үзләре тарафыннан үткәрелә торган нейтралитет политикасының „үзгәртелмәячәге“ турында белдерүләр ясарга мәҗбүр итә. Аннан соң бу кешеләр Скандинавиядә сугыш хәрәкәтләре мәйданы хәзерләү планнарын бик тиз ачу, Германия тарафыннан тиешле реакцияне китереп чыгарыр дип тә куркалар.

СССР га каршы сугыш китереп чыгару теләге белән Скандинавия матбугатында Советка каршы алып барыла торган котырынган кампания уңае белән СССР ның Швециядәге һәм Норвегиядәге илчеләренең белдерүләренә җавап итеп тә бу илләрнең хөкүмәтләре нейтралитетны сакларга уйлаулары турында шундый ук белдерүләр ясадылар.

Совет хөкүмәтенең белдерүләрендә, Швециянең һәм Норвегиянең СССР га карата агрессив теләкләре барлыкны күрсәтә торган фактлар китерелгән иде. Ак Финляндиягә ярдәмгә „доброволецлар“ туплау өчен Швециянең һәм Норвегиянең күп кенә шәһәрләрендә вербовка пунктлары оештырылу, буржуаз матбугатның ачыктан-ачык СССР га каршы сугышка өндәве, Швециядән һәм Норвегиядән Рюти-Таннер хөкүмәтен корал белән тәэмин итеп тору—бу фактлар барсы да Скандинавия илләре иглан иткән нейтралитет политикасына тупас рәвештә каршы килеп кенә калмыйлар, хәтта аларның көтелмәгән кыенлыкларга китерүләре һәм СССР белән Скандинавия илләре арасындагы нормаль мөнәсәбәтләрне бозулары мөмкин.

Совет хөкүмәтенең белдерүләренә Швециянең һәм Норвегиянең биргән җавапларының аларның сугыш уты кабызучы империалист хуҗаларының кушулары буенча төзелгәнлеге ачыктан-ачык күренеп тора.

Скандинавия илләре үзләренең нейтралитет саклаулары турында ни кадәр генә ышандырырга тырышсалар да, Совет хөкүмәтенең белдерүенә биргән җаваплары һич тә мондый ышанычны бирми. Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренең позициясендә сугыш үзәкләрен җәелдерү куркынычы бар.

Германия матбугаты Скандинавия илләрендә Маннергеймга ярдәм флагы астында алып барыла торган чараларны бик нык күзәтеп тора. Германия матбугатында басылып чыккан күп кенә мәкаләләрдә, Швецияне һәм Норвегияне Бөек Британия вассалларына әврелдерү планнарына һәм шул юл белән Германиягә каршы сугышны киңәйтүгә Германиянең игтибарсыз карамаячагы әйтелә.

Чит ил матбугатында Англия һәм Франция Скандинавия илләре хөкүмәтләреннән корал төягән транспортлар үткәрүне таләп итәргә уйлыйлар дигән хәбәрләр чыккан иде. Шул уңай белән Германия матбугаты, монда сүз Скандинавия илләрендә союзникларның тәҗрибә сугыш базаларын төзү турында бара дип язды.

Германия газеталарының язуына караганда, Англиянең һәм Франциянең мондый чаралары Финляндиягә „ярдәм“ күрсәтүдән бигрәк, Скандинавия илләренә союзникларның басымнарын көчәйтүне күздә тоталар.

Скандинавия матбугаты, Скандинавия илләре тарафыннан Финляндиягә күрсәтелә торган „частный“ ярдәм—бу илләр Англияне һәм Францияне яклап чыгалар дигән сүз түгел дип белдерде. Ләкин Швеция һәм Норвегия газетачылары никадәр генә боргалансалар да, Англиянең—Франциянең корал транспортларын Скандинавиягә үткәрү турындагы мәсьәләнең матбугатта куелуы үзе үк Англия—Франция империализмының сугышны киңәйтү турындагы планнарының никадәр тирән киткәнлеген күрсәтә.

Сугыш пропагандасы һәм сугыш хәзерлекләре уңае белән килеп чыккан ачуны йомшарту өчен Швециянең хөкүмәт матбугаты соңгы вакытларда „Финляндия мәсьәләсендә Швеция политикасы бары тик Швеция интереслары белән генә чикләнә“ дип кат-кат яза башлады.

Скандинавиянең коммунистлар матбугаты „Швеция интереслары“ дигән нәрсә артында нинди планнар яшеренеп ятканлыкны бик нык фаш итә. „Ню-даг“ газетасы, Британия империализмының һәр вакытта да үзенә солдатларны сатып ала белгәнлеген һәм үзенең интереслары өчен башка халыкларны кан коярга мәҗбүр итә белгәнлеген яза. Газета болай ди: „Швеция буржуазиясенең Маннергеймга ярдәм күрсәтү планнары артында Лондон тора. Британия империализмы Швеция халкын, шулай ук башка халыкларны да, үзе өчен уттан борчак чүпләргә мәҗбүр итмәкче була. Без Швеция буржуазиясе „патриотизмының“ чын бәясен беләбез“.

Швециянең коммунистлар партиясе, империалистларның хәйләкәр уеннарын хезмәт ияләре массасына һәр вакыт аңлатып килә. Ул, Швеция халкына Скандинавия илләрен сугыш мәйданына әйләндерүгә каршы, тынычлык өчен көрәшергә чакырып мөраҗәгат итә. Скандинавия илләрендәге хезмәт ияләренең тынычлыкка омтылулары һәм Финляндиянең Халык хөкүмәтенә аларның мәхәббәте—империалистларның сугышны киңәйтү планнарын тормышка ашыруга тоткарлык ясый торган иң көчле фактор.

К. Гофман.

ТАТАРСТАН КОЛХОЗЛАРЫНДА

Сарык асрауда минем тәҗрибәм

ӘЛМӘТ. (Телефон буенча). Мин сарык тәрбияләү эшендә 1934 нче елдан бирле эшлим инде. Зоотехника кагыйдәләрен дөрес куллану нәтиҗәсендә, сарык үстерү, аның нәселен яхшырту терлекчелекне күтәрүдә зур уңышлыкларга ирештем.

1934 нче елда мин эшли башлаган фермада 150 баш сарык бар иде. Хәзер безнең фермадагы сарыклар саны 308 башка җитте. Аларның күпчелеге метис. Саф канлы чын меринос сарыклары да аз түгел. 1937 һәм 1938 нче еллардагы уңышлы эшләрем өчен мин үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнаштым. 1940 нчы елда да күргәзмәгә катнашу өчен кандидат итеп теркәлдем.

Үткән ел мин 160 баш сарыктан 222 бәрән үстерүгә ирештем. Безнең уңышлыкларыбызның сере нәрсәдә соң? Аның сере катлаулы түгел. Сарыклар яхшы үрчесен өчен, терлекчелек алга китсен өчен терлекләрне үрнәк рәвештә тәрбияләргә кирәк. Алар чиста, тук, көр булсыннар. Ә бу инде терлекләрне вактында ашатуны, эчертүне, торакларның чиста, җылы булуын таләп итә. Азыкны үз вактында бүлеп бирә белү, аның төрле булуы бик зур урын тота. Без сарыкларга берничә төрле азык бирәбез. Җылырак көннәрне иртәнге 4 сәгаттә сарыкларны кардага чыгарабыз. Иртән ашар өчен арыш саламы таратабыз. 2—3 сәгаттән соң аны җыеп алабыз да шунда ук сабан ашлыгы саламын бирәбез. Ә көндезге сәгат 11 дә инде кибәккә кушабыз. Сәгат 12 дә сарыкларны эчертеп һәрбер сарык башына 200 грамм, буаз сарыкларга 500 грамм бөртекле ашлык бирәбез. Сарыклар җылы көннәрдә көн буена ачык һавада булалар.

Чаптыру кампаниясенә хәзерлек һәм аны үткәрү терлек үрчетүдә иң әһәмиятле чараларның берсе булып тора. Без чаптыру кампаниясен август һәм сентябрь айларында үткәрәбез. Бу эш башланганчыга кадәр ике ай алдан бәрәннәрне сарыклардан аерабыз һәм көтүне яхшырак җирләргә чыгарабыз. Чаптыру кампаниясе вактында ясалма орлыкландыруны да нык кулланабыз. Моның ике төрле файдалы ягы бар. Беренчедән, ул сарыкларны имгәтүдән саклый. Ә икенчедән, ясалма тәртиптә каплатылган сарыкның бәрәне таза, көр була һәм җитез үсүчән була.

Мин 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә яңа уңышлар белән бару өчен барлык чараларны күрәм.

Хәйбрахман Гарифуллин.

Әлмәт районы, „Яңа Тормыш" колхозы члены.

ПРОИЗВОДСТВОДА ЭШЛӘҮ КҮҢЕЛЛЕ

Производствода агрономның роле үскәннән-үсә бара. Безне, агрономнарны, авыл хуҗалыгы производствосының инженерлары дип дөрес атыйлар. Без бу мактаулы исемне акларга тиешбез.

1926 нчы елдан бирле агроном булып эшләү вактымда миңа 1932 нче елдан 1936 нчы елга кадәр Татнаркомзем аппаратында эшләргә туры килде. Ул еллар искә төшкәндә, дөресен әйтергә кирәк, аппаратның мине статистик-гостролер итүе хәтергә килә. Бүлек җитәкчесенең заданиесе буенча теге яки бу районга командировкага барасың. Районда тикшеренгән буласың, агрономнар башкарган эшне фотографиялисең, ә соңыннан акт төзисең. Бу актның күләме никадәр зуррак булса, шул кадәр яхшырак эшләгән булып күренәсең. Озак вакыт шәһәрдән чыкмый торсаң, колхоз производствосы тормышыннан артка каласың, урыннарга баргач, бу бик нык сизелә иде. Аппаратта эшләүнең миңа тәэсире менә шулай иде.

Производствода эшләү аппаратта эшләүгә караганда күп яхшы, үзең дә, кеше дә канәгатьләнә. Колхозда эшләгәндә без, агрономнар хезмәтебезнең җимешләрен үз күзебез белән күрәбез.

Минзәлә районында мин 5 ел эшлим. Иптәшләр дә күптәннән эшлиләр. МТС ның өлкән агрономы иптәш К. Г. Иксаков, агроном Костромин һәм агроном Орлов иптәшләр һәм башкалар безнең районда 7 елдан артык эшлиләр. Шушы чор эчендә колхозларда безнең ярдәмебез буенча агротехника чаралары куллану буенча күп кенә файдалы эшләр башкарылды. Элек районда орлыкларны агулау 35 проценттан артмаган. Чәчүлек орлыкларның 39 проценты гөмбә авыруы белән зарарланган иде. Соңгы 3 ел эчендә барлык орлыкларны агулау үткәрелде. Хәзер гөмбә белән зарарлану 3 проценттан артмый, күпчелек колхозларда исә ул 1 процентка да җитми.

Соңгы елларда без 200 дән артык яровизатор кадрлары хәзерләдек. Алар академик Лысенконың шәкертләре, алар үзләренең планнарын ел саен арттырып үтиләр. Производстводагы агрономнар элек колхозларда кулланылмаган күп кенә өр яңа чараларны: шакмаклап чәчү, уҗым тырмалау, мульчировать итү һ. б. үткәрүнең алдынгылары булдылар. Үткән елларда безнең колхозлар агрономия чаралары кулланып, корылыкка каршы зур көрәш алып бардылар. 1937 һәм 1938 нче елларда бөртекле культуралар буенча иген уңышын гектарына 12 центнердан артык алганлыклары өчен район агрономнары Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнаштылар, зур белем, тәҗрибә мәктәбен үттеләр.

Агрономия эшендә бик күп мәтур нәрсәләр очрый. Бездә тәҗрибәче колхозчылар тарафыннан тупланган бик күп мәгълүматлар бар. Без фән работникларыннан аерылмыйбыз, академик В. П. Мосолов һәм доцент М. В. Марков белән ныклы элемтә тотабыз.

Көнкүреш ягыбыз да яхшы. Безнең барыбызга да яхшы квартиралар бирелде. Аерым алганда, минем үзем өчен махсус рәвештә дүрт бүлмәле квартира эшләтеп бирделәр. Квартирада электро һәм радио. Кичләрен укыйм. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнүне тәмам иттем инде. Хәзер беренче чыганаклар буенча өйрәнәм. Агрономнарның барсы да транспорт белән тәэмин ителгәннәр. Ә җәй көне өлкән агроном җиңел автомашинадан файдалана.

Ләкин әле бездә агрономнар җитми, чөнки ВУЗ ларны һәм техникумнарны тәмам итүче белгечләрнең күбесе өлкә аппаратында утыралар. Безгә орлыкчы, энтомолог һәм участкы агрономнары кирәк. Без производствога, үзебезнең агрономнар семьясенә шәһәрдән агрономнар көтәбез.

П. Ерашов.

Минзәлә район җир бүлегенең өлкән агрономы.

Йөкләмәләрне намус белән үтәргә

Буденный районының барлык колхозлары Сталинград өлкәсе бригадирларының һәм Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөраҗәгатенә кушылып, 1940 нчы елда Сталинчыл югары уңыш алуга ирешү буенча конкрет йөкләмәләр алганнар иде.

Алган йөкләмәләрен үтәү өчен тиешенчә көрәшүче „Красный Яскул", „Красный Мөртле" һәм кайбер башка колхозлар язгы чәчүгә хәзерлекне тулысынча төгәлләделәр. Кышкы агротехника чараларын үткәрү планы үтәлгән. Югары уңыш өчен көрәштә бригадалар һәм аерым колхозчылар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелгән.

Ә алган йөкләмәләрне конкрет эш белән ныгытмаучы колхозларда, киресенчә, язгы чәчүгә хәзерлек эшләре гафу ителмәслек акрын бара. Агрономия чараларын үткәрүгә игътибар ителми. Районда кар тоту планы 50 процент, кырга тирес чыгару бары 16 процент үтәлгән. Көл җыю 8.000 центнер урынына 689 центнер, кош тизәге һәм фекали 3 әр мең центнер урынына 285 әр генә центнер җыелган.

Кайбер колхозларның җитәкчеләре язга хәзерләнүдә һичбер җаваплылык сизмиләр. „Гигант № 1" колхозының председателе Гарифуллин агротехника чараларын үткәрүгә ачыктан-ачык тоткарлык ясый. Бу колхозда кырга бары 70 йөк тирес чыгарылган, ә план буенча 800 йөк! Кар тоту, урындагы ашламаларны җыю эшенә әле бөтенләй керешелмәгән. Агрономия укулары оештырылмаган.

Киров исемендәге колхозда да (председателе Кирилов) шундый ук хәл. Бу колхоз районның орлыкчылык колхозы. Ул районның башка колхозларын сортлы орлыклар белән тәэмин итәргә тиеш. Биредә агроном бар. Ләкин колхоз председателе һәм агроном иптәш Шәмсеттиновның җавапсызлыклары, югары уңыш өчен көрәшкә киң колхозчылар массасын оештырмаулары сәбәпле кар тоту планы 18, кырга тирес чыгару планы 10 процент кына үтәлгән. Агротехника укулары көз көне үк башлануга карамастан, 3 кенә занятие үткәрелгән.

Шулай ук „Путь Сталина", „Красная Канова" колхозларында кышкы агротехника чараларын үткәрү, гомумән чәчүгә хәзерлек бик начар тора. „Красная Канова" колхозы агротехнигы Мясников хезмәт көннәренә „экономия ясыйбыз" дигән марка астында кар тотуга комачаулык итеп килә. Колхоз правлениесе бу кешегә, бер нәрсә дә эшләмәвенә карамастан, ай саен 37,5 хезмәт көне яза.

„Ирек" һәм Буденный исемендәге колхозларда кар тотуның сыйфатына әһәмият бирмиләр. Кар өемнәре һәр гектарда кимендә 180—200 урынына 30—50 өемгенә. Ә колхоз җитәкчеләре моны „күрмәгәннәр" һәм бу эштә булучыларга хезмәт көннәре тулы язганнар.

Колхозларда агротехника укуларының барышы аеруча начар. Райондагы 19 колхозда әле дә түгәрәкләр юк. Оештырылган түгәрәкләрдә дә занятиеләр бик сирәк була.

А. Яфизов.

ТАТАРСТАН СОВНАРКОМЫНДА

Татарстан Совнаркомы төзү материаллары предприятиеләрен 1940 нчы ел сезонына хәзерләү турындагы мәсьәләне карады һәм 1940 нчы елны төзү материаллары җитештерү программасын үтәүне тәэмин итү теләге белән махсус карар чыгарды.

Совнарком заводларны сезонга хәзерләү буенча конкрет чаралар билгеләде. Бина эченә урнаштырылган җиһазларга (прессларга, балчык изгечләргә, двигательләргә һ. б.) ремонт ясау эше 1 нче февральгә, юл хуҗалыгына ремонт ясау эше 20 нче апрельгә һәм киптерү хуҗалыгына ремонт ясау эше 20 нче мартка төгәлләнергә тиеш. Торакларга ремонт ясау, эшчеләр һәм колхозчылар белән договорлар төзү буенча да ныклы сроклар билгеләнде.

Совнарком район предприятиеләрен ныгытуга, аларның финанс хәлләрен яхшыртуга зур игътибар бирә. Мәсәлән, район башкарма комитетлары карамагындагы төзү материаллары промышленносте предприятиеләренең финанс хәлләрен яхшырту теләге белән быел I нче кварталда аларга 200 мең сум күләмендә аванс бирергә билгеләнде. Шулай ук төзү материаллары промышленносте предприятиеләрен эш көчләре белән һәм ягулык белән тәэмин итү буенча да чаралар күрелә. Беренче кварталда предприятиеләргә, еллык фонд исәбеннән, 36 мең кубометр утын җибәрелә. Предприятиеләрне эш көчләре белән тәэмин итү өчен, төзү материаллары промышленносте идарәсе һәм Татстройматсоюз үзләренә беркетелгән районнарда эшчеләр тупларга тиешләр.

Эш белән җавап бирәләр

Казан—Чистай—Бөгелмә трактын төзекләндерү турында Столбище районы колхозчылары мөраҗәгатенә Лаиш районы колхозчылары конкрет эш белән җавап бирәләр. Алар бу гүзәл хәрәкәткә кушылган хәлдә, төзү материалларын эш объектларына ташуны соңгы көннәрдә аеруча көчәйттеләр. Нариманов исемендәге колхозда юл төзелеше буенча махсус бригада оештырылды. Бу бригадага колхозның атаклы стахановчысы иптәш Денисов җитәкчелек итә. Бригада практик эшкә кереште. Таш һәм ком ташу эшен башкаручы возчиклар үзләренең көнлек нормаларын системалы рәвештә 150—200 процентка җиткереп үтиләр.

Татсаралы, Нарманка, Средне-Девятово, Лаиш авылы колхозчылары да ярышта алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр.

Юл төзелеше эшенә авыл интеллигенциясе дә зур булышлык күрсәтә. Мәсәлән, Лаиш авылының укытучылары, врачлары һәм барлык хезмәткәрләр „13 лет Октября" артеле колхозчыларының мөраҗәгатен махсус җыелышта тикшерделәр. Алар хәзер гомуми ял көннәрендә Чкаловск трактында эшләүчеләргә культура хезмәте күрсәтә башладылар.

А. Чистайлы.

ХАТЫН-КЫЗЛАРДАН ТРАКТОРЧЫЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ ЭШЕ ӨЗЕКЛЕКТӘ

Хатын-кызлардан тракторчылар, комбайнчылар кадрлары хәзерләү гаять әһәмиятле эш. Ләкин Шөгер районының Үзәк МТС ы җитәкчеләре (директоры Газизов, политик эшләр буенча аның урынбасары Хәлимев иптәшләр) бу өлкәдә үзләренә төшкән җаваплылыкны хәзергә кадәр аңлап җиткермәгәннәр. Биредә бу эшне икенче дәрәҗәдәге эш итеп караганнар, үз агымына куйганнар. Дөрес, бу турыда күп кенә җыелышларда, киңәшмәләрдә байтак сөйләнгән, озын-озын карарлар да кабул ителгән, ә практик эш бөтенләй эшләнмәгән диярлек.

ВЛКСМ райкомы һәм МТС планы буенча Кәркәле һәм Сугышлы авылларында производстводан аермыйча хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү өчен курслар оештырылган булган. Бу авыллардагы комсомол оешмалары һәм колхоз правлениеләре булышлыгы белән укучылар тупланган һәм бу курсларның берсендә 6 занятие, ә икенчесендә оештыру занятиеләре үткәрелгән. Тракторны өйрәтү өчен хәзерлекле механик та билгеләнгән булган.

Ләкин МТС җитәкчеләре бу курсларга мөдирләр һәм гомуми фәннәр буенча укытучылар билгеләү турында онытканнар. Шуның нәтиҗәсендә, курслар нормаль эшләмиләр, Кәркәле авылындагы курста кайбер укучылар укудан бөтенләй туктаганнар. Курслар уку-укыту әсбаплары белән бөтенләй тәэмин ителмәгәннәр диярлек.

ВЛКСМ ның Шөгер райкомы, район җир бүлеге һәм Үзәк МТС ы җитәкчеләре производстводан аермыйча хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү эшен үз агымына куярга ярамавын аңларга, аңа большевистик җитәкчелек итәргә, югарыда күрсәтелгән барлык җитешсезлекләрне кичекмәстән бетереп, оештырылган курсларның яхшы эшләүләрен тәэмин итәргә тиешләр.

И. Узбеков.

Биектау районы, Буденный исемендәге колхозның агротехнигы И. С. Морозов (сулда) һәм МТС агрономы Н. И. Рыжнов иптәшләр чәчүлек бодаен тикшерәләр. И. Галиев фотосы.

КҮЧМӘ КЫЗЫЛ БАЙРАК ӨЧЕН КӨРӘШ

1939 нчы елның апрель көннәре. Серго Орджоникидзе исемендәге заводның партия, профсоюз комитетларының һәм завод дирекциясенең күчмә кызыл байрагын булдыру турындагы хәбәр цехларга һәм бүлекләргә тизлек белән җитә. Кызыл байракны яулап алу өчен һәр җирдә ныклы көрәш башлана. Цехларда, мастерскойларда, бригадаларда һәм аерым кешеләр арасында социалистик ярыш договорлары төзелә, яңадан-яңа йөкләмәләр алына, аларны үтәү өчен конкрет чаралар билгеләнә. Бар җирдә дә иҗад эше, хезмәт энтузиазмы киң колач җәя.

Кешеләр ай буена ярышып эшлиләр. Кем алдынгылыкны алыр? Кызыл байракны яулап алуга кем ирешер? Күпләр, бик күпләр шул турыда уйлыйлар, ярышалар, алдынгылыкны даулыйлар.

Ярыш һәр эш тармагында гүзәл нәтиҗәләр бирә. Күп кенә цехлар айлык программаны югары сыйфат күрсәткечләре белән арттырып үтәүгә ирешәләр. Бер айлык хезмәткә йомгак ясала, эшнең нәтиҗәләре тикшерелә. Барлык күрсәткечләрне исәпләгәннән соң, җиңү Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге ярышның инициаторы булган механика цехы коллективы ягында икәнлеге билгеле була. Цех коллективына заводның күчмә кызыл байрагы тапшырыла.

Күчмә кызыл байракны тапшыру завод тормышында зур вакыйгага әйләнә. Социалистик ярыш дулкыны барлык эш участокларын чолгап ала. Стахановчылар, инженерлар, техниклар кызыл байракны яулап алу өчен тагын да зуррак дәрт һәм энергия белән эшли башлыйлар. Начальнигы иптәш Главацкий булган цех коллективының инициативасы буенча май аеның ахрында цехлар тарафыннан алынган производство йөкләмәләренең үтәлешенә үзара тикшерү үткәрелә.

Июль аеның беренче көннәре. Күп кенә цехлар ярышта зур уңышларга ирештеләр. Ләкин күчмә кызыл байракны кемгә тапшыру мәсьәләсен хәл итүне завком озакка суза. Цех работниклары моңа түзмичә, завком работникларын тәнкыйтьләп чыгышлар ясыйлар. Һәм бик урынлы рәвештә бу мәсьәләне тизрәк хәл итүне таләп итәләр.

Тик 25 нче июльдә генә завком пленумы бу мәсьәләне карый һәм кызыл байракны иптәш Абецедарский начальник булган цехның коллективына тапшыру турындагы фикергә килә. Ләкин завком икенче көнне башка карар чыгара... Кызыл байраклы цехның июнь аенда тагын да зуррак уңышларга ирешкәнлеге билгеле була һәм күчмә кызыл байрак яңадан иптәш Главацкий начальник булган цехта калдырыла.

Кызыл байракны яулап алу өчен яңадан көрәш башлана. Иптәш Абецедарский начальник булган цехның коллективы кызыл байракны яулап алу өчен көрәштә аеруча зур оешканлык күрсәтә. Продукция эшләп чыгаруда гаять зур уңышларга ирешә һәм күчмә кызыл байрак иптәш Абецедарский начальник булган цех коллективына тапшырыла.

Иптәш Медведский начальник булган цех коллективы август аенда беренче тапкыр үзенең эшендә кискен борылыш ясый, артта баручы цех дигән тапны бетерә. Механика цехына караганда да югарырак күрсәткечләр бирә. Кызыл байрак шушы цех коллективына күчә.

Цехта зур җаңлылык. Президиум өстәле янында мактаулы кызыл байрак. Митингта чыгып сөйләүче стахановчылардан Ведерников, Свяховский һәм башка иптәшләр яңа йөкләмәләр алалар, сентябрь аенда тагын да яхшырак эшләргә сүз бирәләр. Ләкин цех җитәкчеләре кызыл байрак алу нәтиҗәсендә туган хезмәт күтәренкелеген уңышларны ныгыту өчен җитәрлек файдаланмыйлар. Нәтиҗәдә, сентябрь ае ярышында механика цехы яңадан алдынгылыкны ала һәм кызыл байракны яңадан үзенә кайтара.

1940 нчы ел механика цехында аеруча зур шатлык белән каршы алына. Сентябрь, октябрь, ноябрь һәм декабрь айларында бу цех коллективы кызыл байракны үзендә саклап кала.

3 нче гыйнвар. Декабрь ае өчен цехлар арасындагы ярышка йомгак ясала. Кызыл байракны алуга берничә цех кандидат булып тора. Шулар эчендә иптәш Алешин начальник булган цех та бар. Ул декабрь аенда яхшы эшләгән. Ләкин бу цехның эш методларында штурмчылык бетмәгән һәм продукциянең сыйфатына җитәрлек әһәмият бирелмәгән әле. Өстенлек тагы механика цехында кала.

1939 нчы ел эчендә кызыл байрак өчен көрәш завод коллективын зур җиңүләргә китерде. Заводның чыгарган продукциясенә илебез, партиябез тарафыннан бирелгән зур бәя заводта эшләүчеләрнең барсы өчен дә гаять зур шатлык булды.

Инженерлар, техниклар, стахановчылар үзләренең иҗад көчләрен күчмә байракны тагын да югарырак күтәрүгә хезмәт иттерделәр. Уйлап табучылар, рационализаторлар 1939 нчы ел эчендә үзләренең рационализация тәкъдимнәрен тормышка ашыру нәтиҗәсендә, заводка 2 миллион сум экономия бирделәр. Рационализатор мастер иптәш Денисовның үзелларның технология процессын үзгәртү турында биргән тәкъдиме үзе генә дә заводка 150 мең сум экономия бирде. Бер детальнең конструкциясен үзгәртү турында мастер Афонинның биргән тәкъдиме һәрбер изделияне эшләү буенча 25 килограмм кыйммәтле металга экономия ясарга мөмкинлек бирде. Шәһәр Советы депутаты Смирнов, токарь Пирогов, фрезеровщик Лисин, слесарь Ухарский иптәшләр һәм башкалар үзләренең рационализация тәкъдимнәре белән хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә заводка гаять зур файда китерделәр.

Һәрбер цехта, һәрбер бригадада хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча 5 еллык планны 4 елда төгәлләү өчен көрәш башланды, яңа йөкләмәләр алына.

Кызыл байрак алган механика цехында катлаулы махсус станокларны үзләштерү, автомат станоклардан тулысынча файдалану, эшчеләрнең квалификацияләрен күтәрү юлы белән хезмәт җитештерүчәнлеген 2—3 тапкыр арттыруны тәэмин итәрлек конкрет эш планы төзелде.

Начальнигы иптәш Н. Закутаев булган цехта хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча күрелгән чаралар аеруча зурлар. Цехта детальләрне буяу буенча кул хезмәте механизация белән алмаштырыла. Эш башыннан эшләүгә күчәләр. Бракка чыккан детальләрне яраклыга әйләндерү эшенә керештеләр.

Ремонт-механика цехы 1940 нчы ел эчендә хезмәт җитештерүчәнлеген узган елга караганда 20 процентка күтәрүне билгеләде. Бу бурычны үтәү—берничә станокта эшләүчеләрнең санын арттыру һәм эшсез торуларны бетерү юлы белән барачак.

Иптәш Глазков начальник булган цехта искергән нормаларны үзгәртү буенча конкрет эш башкарыла. Элек эш нормасы буенча 30 сәгать вакыт билгеләнгән детальгә хәзер 20 сәгать вакыт куелды. Берничә профессияне үзләштерүдә беренче адым ясалды. Кешеләр бер үк вакытта берничә төрле эш алып баралар.

Кызыл байрак өчен көрәш завод коллективын хезмәт җитештерүчәнлегенең 5 еллык планын 4 елда үтәүгә туплый. Аны яулап алу өчен көрәш завод коллективының быел да зур җиңүләргә ирешүен тәэмин итәр.

С. Кәримуллин.

Г. Рафик.

Делегатлар килә башлады

Социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсенә катнашу өчен делегатлар килә башладылар. Кичә Мамадыш, Октябрь, Акташ һәм Әгерҗе районнары делегатлары килделәр. Алар арасында Мамадыш районының „Хәсәнша" колхозы председателе Салих Казыйханов, Молотов исемендәге колхоз агротехнигы Г. Зайцев, „Оборона" колхозы звено башлыгы Мәһитап Әхметова, Октябрь районының „Приютовка" колхозы председателе Евдокимов һәм агрономнар, зоотехниклар һ. б. бар.

Алар барсы да социалистик авыл хуҗалыгында эшләп, стахановча хезмәтнең чын үрнәкләрен күрсәткән, Сталинчыл югары иген уңышы өчен, терлекчелекне үстерү өчен көрәштә гүзәл нәтиҗәләргә ирешкән алдынгы кешеләр. Салих иптәш Казыйханов җитәкчелек итә торган „Хәсәнша" колхозы (Мамадыш районы) 1939 нчы елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 13 центнер, арышның һәр гектарыннан 17 центнер уңыш алуга ирешкән. Аерым участокларда уңыш гектарына 22,36 центнерга җиткән. Иптәш Евдокимов җитәкчелегендәге „Приютовка" колхозы (Октябрь районы) югары уңыш алуга ирешүе өчен Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашкан һәм күргәзмәнең баш комитеты тарафыннан икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләнгән.

Киңәшмәгә авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан 500 дән артык кеше катнашачак. Киңәшмәгә Чувашстан һәм Марий республикаларыннан кунаклар киләчәк.

Пожарский. (Республиканың халык артисты—орденлы Б. Н. Ливанов).
ТАСС фотохроникасы.

КИНО

„Минин һәм Пожарский“

XVII нче гасырның башы халык өчен аеруча авыр булды. Өч ел буенча дәвам иткән ачлык һәм ил эчендә барган узара талашлар нәтиҗәсендә дәүләт зәгыйфьләнгән иде. Рус дәүләтенең иске дошманнары булган Польша паннары шушы авыр вакыттан файдаланып калырга һәм Россияне коллыкка төшерергә омтылдылар. Арган, йөдәгән халык, сатлык боярларның хиянәте аркасында, чит ил юлбасарларына—интервентларга тиешле отпорны бирә алмады. Польша паннары Смоленскине алдылар. Шул ук вакытта, Москва хөкүмәтенең көчсезлегеннән файдаланып, төньяктан шведлар килеп Новгородны басып алдылар. Россия авыр көннәр кичерде. 1610 нчы елның көзендә Польша гаскәрләре Москвага керделәр һәм Кремльне алдылар. Польша короле Сигизмундның улы Владиславны сатлык боярлар патша итеп куйдылар.

Ләкин рус халкы бу хурлыкка чыдап тора алмады. Ватанны коткару өчен үзен корбан итәргә хәзер торган халык поляк паннарына каршы күтәрелде.

Новгород кремеле мәйданында гади итче Кузьма Мининнең авазы яңгырады. Ул полякларга каршы көрәш өчен ополчение җыйды. Крестьяннәр, һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр илне саклау өчен акча бирделәр. Халык ополчениегә башлык итеп Москва кнэзе Дмитрий Пожарскине сайлады. Минин һәм Пожарский җитәкчелегендәге зур гаскәр Москвага юл тотты, рус җиренең чын дошманнары булган поляк басып алучыларына каршы сугышка чыкты. Гаять зур оештыру таланты булган, саф күңелле Минин, батыр полководец Пожарский күп төрле халык катлауларыннан төзелгән чуар ополчениене ныклы сугыш көче итеп оештырдылар. Һәм, аерым гаскәр башлыкларының хиянәтләренә дә карамастан, алар ополчениене Москвага алып килделәр.

Москва елгасы буенда рус гаскәре, полякларның гетман Ходкевич командасы астындагы иң зур көчләре белән очрашып, ике арада каты сугыш башлана. Батыр рус гаскәрләре шушы сугышта полякларның төп көчләрен тар-мар итәләр һәм Кремльне алалар.

Бөек илебезнең бөтен халкы Көньбатыш Украина һәм, Көньбатыш Белоруссия халыкларын Польша паннары изүеннән коткару көннәрен шатлык белән үткәргән бер вакытта, ак финнәр, маннергеймнар тырнагыннан хезмәтчел фин халкын азат итү өчен көрәш барган чорда бу картинаның экранга чыгуы бигрәк тә әһәмиятле.

Картина көчле тәэсир белән карала һәм ул тамашачыны нык дулкынландыра. Новгород Кремеленең Собор мәйданында булган халык җыелышы аеруча көчле тәэсир калдыра. Бөек патриот Кузьма Минин Ватанны коткару өчен халыкны чакырып речь сөйли. Россия халыклары илне саклау өчен кыйммәтле нәрсәләрен бирәләр. Хатыннар бердән-бер бәяле нәрсәләре булган алкаларын салып көрәшче Мининга тапшыралар.

В. Шкловскийның сценариясе буенча режиссерлар В. Пудовкин һәм М. Доллер ватаныбыз тарихының бер героик эпохасын кино аркылы бик гүзәл итеп гәүдәләндергәннәр.

Картинаның төп герое булган князь Пожарский образын артист Диванов искиткеч оста һәм табигый итеп уйный. Дмитрий Пожарский ул, гаять акыллы, эчкерсез, нык характерлы, тыныч, ватанга чын күңелннән бирелгән батыр полководец.

Кузьма Минин кыю, талантлы, бик гадый кеше. Минин ролен артист Ханов нак әнә шундый итеп гәүдәләндерә.

Гомумән, барлык артистлар да диярлек, үзләренең рольләрен дөрес һәм оста итеп, тарихи образларны тамашачы алдына җанлы рәвештә китереп бастыралар.

„Минин һәм Пожарский“ картинасы бөек рус халкын, Ватаныбызның җанлы тарихын һәм аның данлыклы батырларын гәүдәләндерә торган фильм.

М. Яхин.

Сугышчының чакыруы

Баулы районының „Большевик“ колхозы стахановчысы иптәш Николай Прокофьевич Багаев 1937 нче елны Кызыл Армия сафына алынган иде. Шушы көннәрдә райвоенкомат аннан хат алды. Иптәш Багаев бу хатны допризывниклар конференциясенә тапшыруны сораган. Үзенең хатында ул болай дип яза:

„Допризывник һәм колхозчы иптәшләр! Финляндиядә эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең ничек яшәгәнлекләрен мин үз күзем белән күрдем. Аларның тормышы кеше тормышына бөтенләй ошамый. СССР дагы колхозчы крестьяннәрнең культуралы таза тормышын Финляндия крестьяннәренең тормышы белән чагыштыруны күңелгә дә китерерлек түгел. Һәм шуның өчен дә без Финляндия хезмәт ияләрен ак бандитлардан коткару өчен бөтен көчебезне куеп көрәшергә тиешбез“.

Иптәш Багаев оборона оешмаларын ныгытырга, призыв башланганга кадәр һәр допризывникның икешәр оборона значогы алуына ирешергә, призывка сәламәт һәм яхшы укый-яза белүче булып килергә Баулы районының барлык допризывникларын чакыра.

Баулы районы допризывниклары конференциясе иптәш Багаевка җавап хаты җибәрде. Допризывниклар бу хатларында конференциядә кабул ителгән конкрет йөкләмәләр турында яздылар.

КОЛЛЕКТИВНЫҢ 75 ПРОЦЕНТЫ ЗНАЧОК АЛДЫ

Казан аэропортының коллективы хәрби эшне зур кызыксыну белән өйрәнә. Аэропорт пилотларының, эшчеләренең һәм хезмәткәрләренең 75 проценты ПВХО значогына нормалар тапшырдылар. Хәзерге вакытта атучылык эшен үзләштерү буенча киң эш җәелде. 15 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына нормалар тапшырды. Төз атучы 10 кешедән команда төзелде, бу команда бөтенсоюз күләмендәге ату ярышларына хәзерләнә.

Аэропортта оборона эшен оештыруда элемтә стахановчысы иптәш Желнов, порт начальнигы ярдәмчесе иптәш Кудряшов, стахановчы—электротехник иптәш Закутилин һәм башкалар зур активлык күрсәтәләр.

133 КЕШЕ „ЯШ МОРЯК“ ЗНАЧОГЫН АЛДЫ

Казан мәктәпләренең укучылары хәрби—диңгез эшен зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Бу эшне өйрәнүгә 600 дән артык укучы тартылды. 25 нче гыйнварда хәрби—диңгез клубы Казанда беренче тапкыр буларак „яш моряк“ значогы алган 133 кешене чыгарды.

Беренче булып значокны 33 нче номерлы мәктәп укучысы Витя Миронов алды. Хәрби—диңгез эше буенча барлык нормаларны ул „отлично“ га тапшырды.

Кызлардан 4 кеше: Казан—Кама Тамагы арасында шлюпка походында катнашучы Леля Катреба, Валя Андреева, Нина Силецкая, Оля Страдомская иптәшләр значок алдылар.

Зур доход

Әлмәт районының „Җәйләү“ колхозы 1939 нчы елда умартачылыктан 24 мең сум доход алды. Умартачылык фермасы мөдире ип. Гөбәйдуллин һәрбер умартадан 62 килограмм бал һәм 1,2 килограмм балавыз алды. Аерым умарталардан 130 ар килограмм бал һәм 4 әр килограмм балавыз алынды.

„Җәйләү“ колхозы умартачылык эшендәге уңышлары белән 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашты һәм 1940 нчы елда күргәзмәгә катнашу өчен кандидат итеп билгеләнде.

(ТатТАСС).

КОЛХОЗ УКУ ӨЕНДӘ

Чаллы районы, Чкалов исемендәге артельнең колхозчылары караңгы төшү белән үк уку өенә киләләр. Биредә кешеләр гадәттә төн уртасына кадәр утыралар. Берәүләр агитаторның беседасын тыңлыйлар, икенчеләре газета укыйлар һәм укыганны үзара тикшерәләр, өченчеләре—биллиард, шахмат, шашка уйныйлар.

Уку өенең активы зур эш алып бара. Избач комсомолец иптәш Г. Хәйруллиннең эшне яхшы куя белүе аркасында, колхозчылар уку өен үзләренең яратып ял итә торган урыннары итеп санийлар.

Менә, очраклы рәвештә сайлап алынган кичләрнең берсе.

Бу кичне уку өендә, гадәттәгечә, репетиция бара—тиздән спектакль булачак. Биредә драма түгәрәге зур популярлык белән файдалана. Колхозчылар инде 50 дән артык спектакль карадылар.

Колхозчы иптәш Г. Мөхәмәтшин үз түгәрәгендә занятие үткәрә. Ул зур дәрт белән винтовканың материаль өлеше турында сөйли. 8 кеше ГТО значогы алырга, 6 кеше „Ворошиловча атучы“ значогын алырга хәзерләнәләр.

Избач иптәш Хәйруллин колхозчыларга яңа газеталар укый, соңгы яңалыкларны сөйли. Аны бик зур игтибар белән тыңлыйлар, уннарча сораулар бирәләр. Колхозчылар Ватаныбызның тормышы белән дә, халыкара мәсьәләләр белән дә үзләренең нык кызыксынуларын күрсәтәләр.

Берничә колхозчы китап алырга килгән. Соңгы вакыт эчендә унлап, китап укып чыккан кохозчы иптәш Р. Ганиева избачтан яңа китап сорый.

— „Корыч ничек чыныкты“ны алыгыз—дип тәкъдим итә избач.

Бу китапны алып, Ганиева шатланып өенә кайтып китә.

Чкалов исемендәге колхоз—районда алдынгыларның берсе. Соңгы өч елда ул гектардан 13 центнердан артык ашлык алды. Терлекчелекне үстерү планын үтәде. Колхозчылар таза һәм культуралы тормышта яшиләр. Һәрбер йорт газеталар һәм журналлар алдыра. Авыл соңгы вакытта 11 тегү машинасы, 9 гармонь һ. б. сатып алды. Хәзерге вакытта колхозчылар рус графикасы нигезендә төзелгән яңа, татар алфавитын өйрәнәләр, агротехника мәктәбендә укыйлар.

А. Куличихин.

САҖИДӘ АПА

Ятим малай Габдулла, әтисен-әнисен юксынып моңайган минутларында, аның итәгенә килеп сарыла торган булган, ә ул Габдулланың башыннан сыйпаган, аңа җылы сүзләр әйткән, аңа өлеш чыгарган.

Ятим малай Габдулла соңыннан җырчы егеткә әверелгән, татар халкының уйларын җырга салып җырлый башлаган, аның тавышы йөрәкләргә үтеп кергән, ләкин шуңа да карамастан, каты әхлаклы дөнья—сәүдәгәрләр дөньясы йомшамаган, җырчы егет ахырында яп-яшь көенчә чехотка авыруыннан үләргә мәҗбүр булган.

Матур сүзе белән күңелләрне күтәреп җибәрүче җырчы егет Габдулла хәзер безнең арабызда юк инде, хәзер халык шагыйре—

Саҗидә апа.

халык җырчысы Габдулла Тукайның мәңге онтылмаслык исме генә калды, мәңге югалмаслык шигърый энҗеләре генә калдылар. Без бүген кайчандыр ятим малай Габдуллага якты чырай күрсәткән һәм үз авызыннан өзеп аңа каптырган анасы Саҗидә апа белән очрашып, Габдулла турында, аның малай чагы турында, аның күргән хәсрәтләре һәм хыяллары турында сөйләшеп утырабыз.

Саҗидә апа Зиннәтуллина—Тукайның әнисе белән бер туган апасы, кечкенә һәм ятим Габдуллага күп кенә хезмәт һәм хөрмәт күрсәткән кеше бүгенге көндә дә исән, Әтнә районы, Каенсар авылы, „Кызыл Яр“ колхозының члены булып тора.

Шушы көннәрдә Татарстан Совет Язучылары Союзында язучылар Саҗидә апа белән очраштылар. Җылы һәм күңелле утырышта, чәй янында, Саҗидә апа үзенең сөекле энесе Габдулла турында бик күп кыйммәтле истәлекләр сөйләде, шагыйрьнең моңа чаклы бер җирдә дә басылмаган, билгеле булмаган хатларын укыды. Габдулла Тукай Саҗидә апага язган хатларының берсендә, „Мошфика*) апаем, синең саби вакытымда һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытасым юк!“ дип яза. Бу яңа истәлекләрдән халык шагыйре Габдулла Тукайның бөек җаны, туганнары белән гаять дәрәҗәдә җылы һәм йомшак мөгамәләдә булуы тагын да тулырак ачылды.

Ф. Х.

*) „Мошфика“ сүзе биредә „шәфкатле“ мәгънәсендә алына.

Дәрестән соң прогулкада (Биектау районы, Буденный исемендәге колхоз). И. Галиев фотосы.

Г. ХАЛИК САДРЫЙНЫҢ ЯҢА УЙЛАП ТАБУЫ

Уйлап табучы Г. Х. Садрый иптәш соңгы вакытта тагын ике яңалык уйлап чыгарды. Бу яңалыкларның Союз күләмендә әһәмияте бар.

Кечкенә елгаларга, буа ясамыйча, двигатель корып, авыл хуҗалыгында кечрәк тегермән, тары яргыч һәм май заводлары шикелле кечкенә предприятиеләрне хәрәкәткә китерү өчен ясалган „канатлы двигатель“ күптән түгел генә Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе тарафыннан кабул ителде. Бу файдалы һәм әһәмиятле уйлап табуы өчен иптәш Г. Х. Садрый Бөтенсоюз Почет Тактасына кертелде һәм Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат итеп билгеләнде.

Иптәш Садрыйның икенче яңалыгы—„Автомат станция“ СССР Элемтә Халык Комиссариаты тарафыннан кабул ителеп, аңа авторлык таныклыгы бирелде.

Хәзер Г. Х. Садрый иптәш Кавказда чәчелә торган культуралы колмакны җыю өчен машина ясау өстендә тәҗрибәләр үткәрә. Бу машинаның моделе инде ясалган.

Иптәш Садрыйның 50 гә якын яңалыгы бар. Шуларның 10 сы Союз күләмендә әһәмияте булган уйлап табулар. Зур экономия бирә торган күп кенә яңалыклар өчен ул „Ударник уйлап табучыга“ дигән көмеш жетон белән бүләкләнде.

Авыл советы председательләре һәм секретарьлаРе өчен курс-киңәшмә

Апаста авыл советы председательләре һәм секретарьлаРе өчен 3 көнлек курс-киңәшмә булып үтте. Район советының башкарма комитеты тарафыннан оештырылган бу киңәшмәдә 32 кеше катнашты. Киңәшмәдә булучылар соңыннан халыкара хәлләр турында һәм революцион законлылык турында докладлар тыңладылар.

Төзүчеләр өчен курслар

14 нче номерлы трестның 3 нче төзү конторасы ташчылар өчен курслар оештырды. Бу курсларда әле генә авылдан килгән 14 эшче өйрәнә. Курсларга шәһәр советы депутаты, ташчы стахановчы иптәш Назаров җитәкчелек итә.

Авылдан килгән колхозчыларга иптәш Назаров үзенең стахановча эш тәҗрибәсен өйрәтә.

7 нче февраль, кич 5 сәгаттә Казан Дәүләт Ветеринария институтының патологик анатомия кафедрасы аудиториясендә институт гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм ветеринария фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, Воронеж Зооветеринария институтында доцент хезмәтен үтәүче В. И. Корольков тарафыннан халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ

үткәрелә

Рәсми оппонентлар: профессор доктор П. Я. Сырнев һәм профессор доктор А. П. Студенцов.

Диссертация материаллары белән институт китепханәсендә танышырга мөмкин.

147—1

КАЗГОРСТРОЙНЫҢ

Труба-Пич эшләре конторасы

1940 нчы елда төтен юлларын чистарту эшләре буенча барлык дәүләт оешмаларының һәм йорт управлениеләренең контора белән

ДОГОВОР ТӨЗҮЛӘРЕН СОРЫЙ

Конторaның адресы: Казан, Островский урамы, 39/6. Телефон 24—89.

146—3—1

ТАТЛЕСДРОМСОЮЗНЫҢ

„ДРЕВПРОМ“ АРТЕЛЕ

шушы ел, 1 нче февральдән

БЕТЕРЕЛӘ

Артельгә карата булган дәгъвалар 1940 нчы ел, 15 нче февральгә кадәр түбәндәге адрес буенча бирелергә тиеш: Казан, Киров урамы, 12.

Күрсәтелгән сроктан соң бирелгән дәгъвалар каралмаячак.

140—3—1

Киров Райпищеторгы 8 нче магазинының югалган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга.

137—1

Татар Дәүләт Опера театры

Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Бүген

КАЧКЫН

Талон 67, 68.

Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.

Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына. Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.

48—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

27 һәм 28 нче гыйнварда

МАСКАРАД

Талоннар: 27 нче гыйнварда 85, 28 нче гыйнварда 86.

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн

Москва 4 нче труппасының гастрольләре

ИНТЕРМЕДИЯ

ЧИК ЙОЗАКТА

Кич 8 дә башлана.

АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы

ЗОЛЛО гастрольләре

Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12-30, 2-45, 7-45 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ТАЙГА ЕРАКЛЫКЛАРЫНДА
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич УКЫТУЧЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	Степан Разин

ИҢ ЯХШЫ ПЬЕСА ӨЧЕН!

Совет драматургиясенең идея, художество сыйфатларын тагын да югарырак күтәрү, илебездә булган гаять күп санлы профессионал театрларның, колхоз-совхоз театрларының һәм үзешчән драма түгәрәкләренең репертуарларын яхшырту, талантлы яңа драматурглар күтәрү, коммунистик җәмгыять төзү өчен барган көрәшне һәр яклап һәм тирән итеп чагылдыру теләге белән Татарстанда, Союзный республикаларда һәм бөтен СССР күләмендә иң яхшы пьесаларга конкурс үткәрелә.

Бу конкурслар, гомуми бер теләктән чыгып үткәрелгәнлектән, барсы да бөтен Союз күләмендә үткәрелә торган гомуми бер чара булып торалар, аерым республикаларда үткәрелә торган конкурслар әнә шул гомуми эшнең бер тармагы төсендә үткәреләләр.

Аерым республикаларда һәм СССР күләмендә үткәрелә торган конкурсларның шартлары, сроклары төрлечә.

Татарстанда үткәрелә торган конкурс ТАССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Идарәсе тарафыннан игълан ителеп, ул 1939 нчы елның 15 нче октябреннән башланды һәм 1940 нчы елның 1 нче апреленә чаклы дәвам итәчәк. Бу конкурс Союз күләмендә үткәрелә торган гомуми конкурсның бер туры булу белән бергә, Татарстан республикасының 20 еллык тантанасына туры китерелеп үткәрелә. Шуңа күрә бу конкурс уңае белән языла торган пьесаларда югарыда әйтелгән гомуми теләк белән бер рәттән, татар халкының иреклe һәм бәхетле тормыш өчен булган көрәше чагылдырылган булырга тиеш.

Бу конкурста яхшы табылган һәм Татарстанның профессионал театрларында куелырлык булып кабул ителгән пьесалар өчен түбәндәге 4 премия билгеләнә:

1 нче бер премия 10.000 сум күләмендә.

2 нче бер премия 7.000 сум күләмендә.

3 нче ике премия 5 шәр мең сум күләмендә.

Ә колхоз-совхоз таетрларында һәм үзешчән драма түгәрәкләре тарафыннан куелу өчен яхшы дип табылган пьесаларга 3 премия билгеләнә.

1 нче бер премия 7.000 сум күләмендә.

2 нче ике премия 3 әр мең сум күләмендә.

Бу конкурска каратылып язылган пьесалар түбәндәге адрес буенча җибәреләләр: Казан, Кремль, Сәнгать Эшләре Идарәсе, конкурс жюриенә.

РСФСР күләмендә үткәрелә торган конкурс 1940 нчы елның 1 нче гыйнварыннан башланып шул елның 1 нче сентябренә чаклы дәвам итә. РСФСР күләмендә үткәрелгән бу конкурста яхшы табылган һәм бүләк алган пьесалар бөтен Союз күләмендә үткәрелә торган конкурска да тәкъдим ителәчәкләр.

РСФСР күләмендә үткәрелә торган конкурс буенча 5 премия билгеләнеп, алар түбәндәгеләр:

1 нче бер премия 25.000 сум күләмендә.

2 нче ике премия 15 әр мең сум күләмендә.

3 нче ике премия 10 ар мең сум күләмендә.

Болардан башка тагы жюри тарафыннан премиягә лаеклы итеп табылмаган, ләкин сәхнәдә куелырга һәм басып таратылырга яраклы табылган яхшы пьесаларга аерым бүләкләр биреләчәк.

РСФСР күләмендә үткәрелә торган бу конкурска пьесалар түбәндәге адрес буенча җибәрелергә тиешләр: Москва, Китайский проезд, йорт номеры 3/4, подъезд 12, РСФСР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Идарәсе.

СССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Идарәсе тарафыннан үткәрелә торган конкурска Союзный республикаларда үткәрелгән конкурсларда сайланып алынып тәкъдим ителгән пьесалар биреләләр. Союзный республикаларның Совнаркомнары янындагы Сәнгать Эшләре Идарәләре икенче тур өчен булган пьесаларны СССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Идарәсенә 1940 нчы елның 1 нче ноябренә тапшыралар.

СССР күләмендә уздырыла торган бу конкурсның нәтиҗәләре 1940 нчы елның 15 нче декабреннән дә соңга калмыйча матбугатта игълан ителәчәкләр. Бу конкурсларда язучылар белән бер рәттән СССР ның барлык гражданнары катнаша алалар. Конкурска СССР да яшәүче халыклар телендә, теләсә нинди телдә һәм жанрда (драма, комедия, водевиль һ. б.) язылган оригинал драматургия әсәрләре кабул ителәләр.

СССР күләмендә уздырыла торган конкурста жюри тарафыннан иң яхшы итеп табылган драматургия әсәрләре өчен түбәндәге 6 премия билгеләнә:

1 нче бер премия 50.000 сум күләмендә.

2 нче ике премия 25 әр мең сум күләмендә.

3 нче өч премия 15 әр мең сум күләмендә.

Әсәрләре премияләргә лаеклы булмаган, ләкин театрларда куелырлык һәм бастырып таратырлык булган авторларга, жюриннең карары нигезендә, 5.000 сум күләмендә бүләк бирелә. Андый бүләкләрнең саны 5. Авторлар конкурсларга үзләренең әсәрләрен бер экземплярда, машинкада бастырып һәм фамилияләрен куймыйча, бары тик девизларын гына куйган хәлдә җибәрәләр. Кульязма белән берлектә, тышына шул ук девизны язып ябык конверт җибәрелә һәм ул конвертның эчендә девиз иясенең чын исемфамилиясе, атасының исеме, тулы адресы күрсәтелгән булырга тиеш.

Бу конкурска әсәрләр Союзный республикалар Совнаркомнары янындагы Сәнган Эшләре Идарәләренә адреслап җибәрелергә тиешләр.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КИРӘК:

„Азат Хатын“ артеленә даими эшкә СКОРНЯКЛАР, МАШИНАДА ТЕГҮЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР, БҮРЕКЧЕЛӘР, ПРОИЗВОДСТВО БУХГАЛТЕРЫ, РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ ӨЧЕН ХИСАПЧЫ, ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ, ЦЕХ БУХГАЛТЕРЛАРЫ һәм скорняк тегү машиналары буенча СЛЕСАРЬ. Хезмәт хакы килешү буенча. 145—2—1

Вахитов исемендәге җиркомбинатка ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОРЛАР, МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЛАРЫ, МАТЕРИАЛЬ ГРУППА ХИСАПЧЫСЫ, ФИНАНСИСТ, ИНЖЕНЕР-МЕХАНИК, ИНЖЕНЕР ТЕХНОЛОГ-ХИМИК, ТЕХНИК-КОНСТРУКТОР-МЕХАНИК, ЧЕРТЕЖЧЫЛАР, БАЛТА ОСТАЛАРЫ, ПИЧ ЧЫГАРУЧЫЛАР, ЯРДӘМЧЕ РАМЩИКЛАР, КОЧЕГАРЛАР, ПРЕССТА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, САНТЕХНИКА БУЕНЧА ИНЖЕНЕР, производство эшләре буенча БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОР, шулай ук ТОКАРЬЛАР, ГЕНЕРАТОРЧЫ ЯРДӘМЧЕЛӘРЕ һәм 3, 4, 5, 6. 7 нче разряд СЛЕСАРЬЛАР. Комбинатның кадрлар бүлегенә килергә. Тукай урамы, 152. 150—2—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А —222 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 349.